ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.04.2020 ел Баулы шәһәре № 90

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 248 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендә кабул ителгән 248 номерлы «Баулы муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карарына (2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Баулы муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәсендә:

III бүлекнең 3.3. пунктындагы 3.3.1. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка җитәкчеләренә, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, педагог-психологларга, кече тәрбиячеләргә,

тәрбиячеләрнең турыдан-туры мәктәпкәчә яшьтәге укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән эшләүче ярдәмчеләренә:

гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәге төркемнәрне дә кертеп):

ике айдан өч яшькә кадәр - 15 бала;

өч яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр - 20 бала;

гаиләдә белем бирү формасындагы төркемнәрдә - 7 бала;

өч яшькә кадәрге һәм аннан өлкәнрәк балалар өчен компенсацияләүче төркемнәрдә:

авыр тайпылышлары булган балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

фонетик-фонематик тайпылышлары булган балалар өчен өч яшьтән өлкәнрәкләр арасында - 12 бала;

саңгырау балалар өчен - ике яшь төркемнәре өчен дә 6 бала;

начар ишетүче балалар өчен - 6 бала һәм 8 бала;

сукыр балалар өчен - ике яшь төркемнәре өчен дә 6 бала;

начар күрүче балалар, амблиопия, кылый балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен - 6 бала һәм 8 бала;

психик үсеш тоткарланган балалар өчен, акылга зәгыйфь балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

акыл ягыннан уртача, авыр дәрәҗәдә артта калган өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен - 8 бала;

аутистик спектрда тайпылышлары булган балалар өчен - 5 бала ике төрле төркем өчен дә;

катлаулы дефектлары булган балалар өчен (физик һәм (яки) психик үсештә ике яки аннан да күбрәк дефекты булган) - ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

катнаш юнәлештәге төркемнәрдә:

өч яшькә кадәр - 10нан да артык түгел, шул исәптән сәламәтлекләре чикләнгән балалар - 3тән дә артык түгел;

өч яшьтән өлкәнрәк:

10нан да артмаган санда, шул исәптән 3 чукрак бала, яки сукыр бала, яки терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, яки акыл ягыннан уртача, авыр дәрәҗәдә зәгыйфь балалар яки аутистик спектрдагы авырулары булган балалар, яки авыр дефектлы балалар;

15тән артык бала, шул исәптән 4тән дә артмаган начар күрүче, амблиопия һәм (яки) кылый яки начар ишетүче балалар, яки сөйләмдә авыр тайпылышлары булган балалар, яки акыл ягыннан артта калган балалар;

17дән артмагын бала, шул исәптән психик үсеше тоткарланган 5тән дә артмаган бала:

өч яшькә кадәрге һәм аннан өлкәнрәк балалар өчен сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә:

туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала;

еш кына авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган башка категория балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала.»;

3.3.2. үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Баулы муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

VIII бүлекнең 8.9 пунктында:

икенче абзацта «җитәкче урынбасарларына билгеләргә» сүзләреннән соң «, баш бухгалтерга» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш бухгалтерга» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта “җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш бухгалтерга» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта "җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш бухгалтерга» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта «җитәкче урынбасарларына» сүзләреннән соң «, баш бухгалтерга» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацта “җитәкче урынбасарларына” сүзләреннән соң “, баш бухгалтерга” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар белән Баулы муниципаль районы Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең VIII бүлеге 8.9 пунктына кертелгән үзгәрешләр 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

3. Әлеге карар белән Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең III бүлеге 3.3.пунктының 3.3.1, 3.3.2. пунктларына кертелгән үзгәрешләрнең 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров